Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

2023 елның 09 октябрендәге № 172

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 10 декабрендәге 111 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАРЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 10 декабрендәге 111 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.4.16. өлешнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- әлеге Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда каралган гавами сервитут һәм (яисә) чикләүләр белән мондый мөлкәткә ия булуны билгеләү турында белешмәләр;

- конкурс шартлары, аларны үтәү рәвешләре һәм сроклары.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н.А. Вазыйхов